**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелә торган чаралар турында мәҗбүри гавами хисабы**

Казан шәһәре
2020 ел

Эчтәлек

1.Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыруны билгеләүче Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары. .............................. 3
2.Сыйфатны бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет (иҗтимагый советлар) турында мәгълүмат. ........................................................................................ 3
3.Социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыюны һәм аны гомумиләштерүне тормышка ашыручы оешмалар турында белешмәләр. ......................................................................................... 4
4.Сыйфатны бәйсез бәяләү уздырылырга тиешле социаль өлкә оешмалары турында мәгълүмат .........................................................................................................5
5.Социаль өлкә оешмаларының хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү йомгаклары ............................................................................................... 11
6.Сыйфатны бәйсез бәяләү йомгаклары буенча социаль өлкә оешмаларының эшчәнлеген камилләштерү өчен күрелә торган чаралар.............................................. 14
7. Халыкка мәгълүмат бирү, аңлату эшчәнлеге..................................................15

1. Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыруны билгеләүче Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары.

1) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 13 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфаты шартларына бәйсез бәяләү уздыру өчен шартлар булдыру буенча чаралар турында» 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы карары;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 7 ноябрендәге 983 номерлы карары;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елга кадәргә чорга Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру буенча чаралар планын раслау турында 2017 елның 26 декабрендәге 3598-б номерлы боерыгы.

2. Сыйфатны бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет (иҗтимагый советлар) турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасында мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү (алга таба – шулай ук СББ) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары) инициативасы буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы карарлары, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарында, шәһәр округларында җирле үзидарә органнары инициативасы (алга таба – Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары) буенча Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары каршындагы иҗтимагый советлар карарлары нигезендә булдырылган сыйфатка бәйсез бәяләү уздыру буенча иҗтимагый советлар тарафыннан тормышка ашырыла.

СББ уздыру буенча иҗтимагый советларның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) СББ уздыру;

2) социаль өлкә оешмалары эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмнарын камилләштерү;

4) социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары турында халыкка мәгълүмат җиткерүне арттыру.

СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәгеләрне тормышка ашыра:

1) аларга карата СББ уздырыла торган оешмаларның исемлеген билгели;

2) эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында документлар проектларын, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыюны һәм аны гомумиләштерүне тормышка ашыручы оешмалар (алга таба – операторлар) белән төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактлар проектларын карап тикшерүдә катнаша;

3) операторлар тарафыннан бирелгән мәгълүматны исәпкә алып СББ уздыра;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына СББ нәтиҗәләрен, шулай ук социаль өлкә оешмалары эшчәнлегенең сыйфатын яхшырту буенча тәкъдимнәр җибәрә.

СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар составлары гамәлдә булган норматив хокукый актлар таләпләренә туры килә һәм аның составына түбәндәге оешмалар вәкилләре керә:

1) гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар;

2) укучыларның һәм (яисә) балигъ булмаган укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар;

3) инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре;

4) ветераннар иҗтимагый оешмалары.

СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар составы турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта www.bus.gov.ru (алга таба –www.bus.gov.ru рәсми сайты), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары) урнаштырыла.

3. Социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыюны һәм аны гомумиләштерүне тормышка ашыручы оешмалар турында мәгълүмат.

Социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыюны һәм аны гомумиләштерүне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары каршындагы иҗтимагый советлар тарафыннан билгеләнгән оешмалар исемлеге нигезендә операторлар тормышка ашыра.

2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары операторлары булып түбәндәгеләр тора:

мәгариф өлкәсендә – «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы;

мәдәният өлкәсендә – «АС-Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

сәламәтлек саклау өлкәсендә – «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә – Татарстан Республикасының «Гаилә канаты астында» төбәк иҗтимагый оешмасы.

Татарстан Республикасы башкарма дәүләт хакимияте органнары тарафыннан операторлар эше өчен бүлеп бирелгән финанс чараларының гомуми күләме 241,99 мең сум тәшкил итә, шулардан мәдәният өлкәсенә – 72 мең сум, мәгариф өлкәсенә – 99,99 мең сум, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсенә – 70 мең сум. Сәламәтлек саклау өлкәсендә оператор эшне халыкка хезмәт күрсәтүне башкармый торган ведомство карамагындагы оешманың дәүләт заданиесе кысаларында алып бара.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә операторларга бүлеп бирелгән финанс чараларының күләме 2 мең сумнан 98,9 мең сумга кадәр үзгәрде. 17 муниципаль берәмлектә операторлар түләүсез нигездә һәм җәмәгать башлангычларында эш алып барды. Муниципаль берәмлекләрдә барлыгы операторлар эше өчен 259,4 мең сум бүлеп бирелде.

Операторлар (операторның атамасы, операторның социаль өлкә тармаклары буенча социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүматны җыю һәм аны гомумиләштерү буенча эш алып бару, хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) контракты номеры) турында мәгълүмат www.bus.gov.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы башкарма дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырылган.

4. Сыйфатны бәйсез бәяләү уздырылырга тиешле социаль өлкә оешмалары турында мәгълүмат.

«Россия Федерациясенең мәдәният турында законнар нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-I номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бер үк оешмага карата СББ уздыру буенча иҗтимагый оешмалар тарафыннан СББ елга бер тапкырдан да ешрак һәм өч елга бер тапкырдан да кимрәк уздырылырга тиеш түгел. Татарстан Республикасында 2020 ел ахырына барлык социаль өлкә оешмаларына СББ уздырылырга тиеш.

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәдәният дәүләт, муниципаль оешмаларында СББ Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын билгеләүче күрсәткечләрне раслау турында» 2018 елның 23 маендагы 317н номерлы карары, Россия Федерациясе

Сәламәтлек саклау министрлыгының «Бәйсез бәяләү уздырыла торган медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын билгеләүче күрсәткечләрне раслау турында» 2018 елның 4 маендагы 201н номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары, урта һөнәри белем бирү мәгариф программалары, һөнәри белем бирүнең төп программалары, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларның мәгариф эшчәнлеген башкаруы шартлары сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын характерлаучы күрсәткечләрне раслау турында» 2019 елның 25 апрелендәге 114 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын билгеләүче күрсәткечләрне раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 599 номерлы карары белән расланган күрсәткечләр буенча уздырылды.

2019 елда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар тарафыннан социаль өлкәгә караган 177 оешмада (әлеге өлкәнең сыйфатны бәйсез бәяләү уздырылырга тиешле оешмаларының 30 проценты), шулардан 12 се – мәдәният оешмасы (28 %), 70 медицина оешмасы (36,8 %), 44 мәгариф оешмасы (20 %), 51 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы (37 %) сыйфатны бәйсез бәяләү уздырылды.

2019 елда социаль өлкәгә караган 1 138 муниципаль оешмада (сыйфатны бәйсез бәяләү уздырылырга тиешле оешмаларның 34,4 проценты), шулардан 141 мәдәният оешмасы (56,2 %), 997 мәгариф оешмасы (30,2 %) СББ уздырылды. 2018–2019 елларда социаль өлкәнең муниципаль оешмаларына СББ уздыру барлыгы 68,4 % тәшкил итте.

2020 елда СББ уздыру планлаштырылган оешмалар барлык оешмаларның гомуми саныннан 30 % тәшкил итәчәк, шул исәптән мәдәният оешмалары – 32,5 %, медицина оешмалары – 36,2 %, мәгариф оешмалары – 28,4 %, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары – 37 %.

2020 елда мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге барлык муниципаль оешмаларның кимендә 35 процентында СББ уздырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы башкарма дәүләт хакимияте органнары каршындагы СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар тарафыннан социаль өлкә оешмаларының хезмәт күрсәтүенә уздырылган СББ йомгаклары уртача түбәндәгеләрне тәшкил итте:

максималь күрсәткеч 100 балл булганда: мәдәният өлкәсендә – 78,7 балл, сәламәтлек саклау – 88,8 балл, социаль хезмәт күрсәтү – 95,12 балл;

максималь күрсәткеч 100 балл булганда: мәгариф өлкәсендә – 96,36 балл.

Татарстан Республикасы башкарма дәүләт хакимияте органнары каршындагы СББ уздыру буенча иҗтимагый советлар тарафыннан социаль өлкә оешмаларының хезмәт күрсәтүенә уздырылган СББ йомгаклары 100 ка тәңгәл булган максималь күрсәткечтә уртача түбәндәгеләрне тәшкил итте: мәдәният өлкәсендә – 77,3 балл; мәгариф өлкәсендә – 69,5 балл.

СББ йомгаклары буенча иң зур баллар түбәндәге оешмаларга бирелде:

мәдәният өлкәсендә (максималь күрсәткеч – 100 балл):

98,62 балл – «Мәскәү» мәдәният үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

97,0 балл – Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы» (район Мәдәният йорты) муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

96,0 балл – «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

95,6 балл – Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Мәдәният сарае» муниципаль бюджет учреждениесе;

95,0 балл – «Казан дәүләт циркы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

94,0 балл – «Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

93,0 балл – «Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

84,0 балл – «Әкият» Татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесе;

83,0 балл – «Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

сәламәтлек саклау өлкәсендә (максималь күрсәткеч 100 балл):

96,38 балл – «Арча үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

95,74 балл – «Диализ клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

95,38 балл – «2 номерлы стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

95,24 балл – «Әлки муниципаль районының Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

95,12 балл – «1 номерлы стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

мәгариф өлкәсендә (максималь күрсәткеч – 100 балл):

100 балл – Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Радуга» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Буратино» гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Солнышко» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең «3 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең «1 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «8 номерлы «Солнышко» гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «7 номерлы «Березка» гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «1 номерлы «Нефтяник» гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет

мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «11 номерлы «Шатлык» катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

98,4 балл – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Г. Баруди исемендәге 4 номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

97,8 балл – Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең «2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мамыково авылының 16 номерлы «Рябинка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең «Буратино» гомуми үсеш төрендәге 12 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

97,2 балл – «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Черемушки урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

96,36 балл – «Чистай балалар йорты» ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет учреждениесе;

95,94 балл – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

95,52 балл – «Казан дәүләт циркы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе (балалар цирк мәктәбе);

94,68 балл – «Республика психология-медицина-педагогика консультациясе» дәүләт казна учреждениесе;

94,66 балл – «Иннополис лицее» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

94,4 балл – «Чаллы шәһәрендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруга ярдәм итү, алмаш гаиләләрне әзерләү һәм аларга күзәтчелек итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә (максималь күрсәткеч – 100 балл):

99,3 балл – «Казан шәһәре» шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

98,8 балл – «Бала-могҗиза» дәвалау педагогикасы үзәге автоном коммерциячел булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы;

98,6 балл – «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

98,2 балл – «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тәтеш муниципаль районындагы «Тәтеш балкышы» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

98,0 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы «Шатлык» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

97,5 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы «Наз» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

97,3 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лаеш муниципаль районындагы «Алтын көз» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

96,9 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

96,8 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы «Шәфкатьлелек үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

96,6 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

96,5 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Бөгелмә муниципаль районындагы «Салават күпере» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

96,4 балл – Казан шәһәренең «Поиск» диагностика һәм консультация үзәге» балаларга ярдәм итү буенча җирле иҗтимагый үзәге;

96,3 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Кайгырту» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, «Наз» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы.

СББ йомгаклары буенча иң аз балл җыючылар:

мәдәният өлкәсендә (иң зур күрсәткеч 100 балл):

73,0 балл – «Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

68,0 балл – «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе, «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

67,0 балл – «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

62,0 балл – «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

61,0 балл – «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

50,56 балл – «Югары Ослан муниципаль районының туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе;

35,0 балл – «Түбән Кама шәһәренең концерт-иҗат үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;

20,72 балл – «Югары Яхшый авыл мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе;

сәламәтлек саклау өлкәсендә (иң зур күрсәткеч 100 балл):

74,8 балл – «Медстом» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

73,32 балл – «Бөгелмә стоматология поликлиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

72,18 балл – «Эллада» медицина технологияләре үзәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

64,14 балл – «БАХИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

мәгариф өлкәсендә (иң зур күрсәткеч 100 балл):

74,30 балл – «Мәктәптән тыш эш республика үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе;

64,0 балл – «36 номерлы кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна мәгариф учреждениесе;

60,44 балл – «Тәрбиягә бала алу, кайгырту һәм попечительлек республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

52,16 балл – «Белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

39,7 балл – Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Тенеш ш.т.п. «Елмаю» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

37,62 балл – Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Лениногорскиның 1 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

29,76 балл – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Гаделша балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

24,80 балл – «Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исемендәге Минзәлә кадетлар мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә (иң зур күрсәткеч 100 балл):

90,6 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

90,3 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы «Кайгырту»

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

84,87 балл – «Ак Чишмә» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

83,5 балл – «Салават күпере» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы;

71,78 балл – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Ал җилкән» сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм үсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

70,72 балл – «Әлки муниципаль районындагы балалар һәм үсмерләр өчен «Каен» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе.

5. Социаль өлкә оешмаларының хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү йомгаклары.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар биргән СББның төп нәтиҗәләре www.bus.gov.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары рәсми сайтларында урнаштырылган.

2019 елда иҗтимагый советларның СББ уздыру эшчәнлеге йомгаклары буенча социаль өлкә оешмалары хезмәт күрсәтү шартлары ягыннан, тулаем алганда, уңай бәяләнде.

Анкеталар тутыру һәм социаль сораштырулар уздыру аша хезмәттән файдаланучыларның социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары турында фикере өйрәнелде. 2019 елда анкеталар тутыруда һәм социаль сораштыруларда 127 063 кеше катнашты.

СББ уздыру барышында ачыкланган җитешсезлекләрнең иң таралганы дип респондентлар түбәндәгеләргә күрсәтте:

1) мәдәният өлкәсендә:

һәркем куллана ала торган мәгълүмат ресурсларында мәдәният оешмалары турында искергән, аңлаешсыз һәм тулы булмаган мәгълүмат бирелгән;

объектларга инвалидлар тоткарлыксыз керә алсын өчен тиешле дәрәҗәдә шартлар булдырылмаган;

2) сәламәтлек саклау өлкәсендә:

медицина оешмасының эшчәнлеге турында һәркем куллана ала торган мәгълүмат ресурсларында урнаштырылган мәгълүматның норматив хокукый актларда каралган мәгълүмат исемлегенә һәм аңа куелган таләпләргә туры килмәве (гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре территориаль программасы кысаларында медицина учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүсез медицина ярдәме турында, аны күрсәткәндә чират көтү һәм медицина кабинетларына юл күрсәтү вакыты турында, медицина оешмалары хезмәткәрләре, аларның белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе турында; хезмәт күрсәтү шартлары, СББ уздыру турында, бәясе күрсәтелгән түләүле медицина хезмәтләре исемлеге, медицина хезмәтләре күрсәтү тәртибе, рәвеше турында

(тарифлар, шартнамәләр үрнәге һ.б.), түләүле медицина хезмәте күрсәтүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренең эш графигы турында мәгълүмат юк);

физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен шартлар тулысынча булдырылмаган (инвалидларның автотранспорты өчен машина кую урыннары, пандуслар куелган керү урыннары, инвалидларга җайлаштырылган лифтлар юк, ишетми һәм күрми торган инвалидлар өчен тавышлы һәм сурәтле мәгълүмат бирелми, мондый инвалидлар өчен рәсми сайтка альтернатив версия эшләнмәгән, һ.б.);

сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында мәгълүмат, медицина оешмасы җитәкчесенең телефоны күрсәтелгән гражданнарны кабул итү графигы, Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең территориаль органы, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белән элемтәгә керү өчен телефоннар күрсәтелмәгән һ.б.;

3) мәгариф өлкәсендә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф оешмасы, аның турында бирелгән мәгълүмат тулы түгел;

объектларга инвалидлар тоткарлыксыз керә алсын өчен тиешле дәрәҗәдә шартлар булдырылмаган;

мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең техник торышы капиталь ремонт уздыруны таләп итә;

4) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

оешмалар биналарында ишетү, күрү ягыннан тайпылышлары булган затлар өчен видео-, аудио- мәгълүмат чаралары тулы күләмдә эшләми;

эчә торган сулы кулерлар өлешчә юк;

шәһәр оешмалары янында, аеруча «Казан шәһәре» шәһәр округында, еш кына машина кую урыннары юк, шул исәптән инвалидлар өчен дә, шул ук вакытта эвакуаторлар эшли;

көннең беренче яртысында гаиләләргә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләре белгечләре уздыра торган күмәк дәресләрнең саны җитәрлек түгел.

Сыйфатны бәйсез бәяләүне уздыру өчен СББ йомгаклары буенча иҗтимагый советлар тәкъдимнәре:

1) мәдәният өлкәсендәге оешмалар буенча:

мәдәният оешмаларының рәсми сайтларын һәм мәгълүмати стендларын тутыруны, шул исәптән «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, законнар таләпләренә туры китерергә;

инвалидлар өчен түбәндәгеләрнең мөмкин булуын тәэмин итү өлешендә җитешсезлекләрне бетерергә:

алмаш урындык-коляскалар сатып алуны күздә тотарга;

аудио- һәм видео мәгълүмат, яктылык таблолары, контраст төсләр белән аеру, тактиль плиткалар һәм сенсор тайпылышлары булган затлар өчен башка чаралар булдыруны тәэмин итәргә;

ишетү, күрү органнары ягыннан инвалидлыгы булган затларга сурдотәрҗемәче (тифлосурдотәрҗемәче) хезмәтләреннән файдалану, шулай ук ерактан торып төрле хезмәт күрсәтүләрдән (виртуаль театр һәм концерт заллары, экскурсияләр, лекцияләр, вебинарлар һ.б.) файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2) сәламәтлек саклау өлкәсе оешмалары буенча:

медицина оешмалары җитәкчеләре белән мәгълүмат стендларында Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә регламентлаштырылган мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү кирәклеге турында селектор киңәшмәсе уздырырга;

планлаштырылган һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр уздырганда медицина оешмаларының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтларында мәгълүмат куелуын тикшерүне тәэмин итәргә;

физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү чаралары күрергә;

3) мәгариф өлкәсендәге оешмалар буенча:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган мәгълүматның тулы һәм яңартылган булуын тәэмин итәргә;

матди-техник базаны ныгытуга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам иттерергә;

хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга, шулай ук мәгариф оешмаларының эшчәнлегенең ачыклыгына юнәлтелгән эшчәнлекне дәвам иттерергә;

сораштырулар уздыру юлы белән хезмәтләр күрсәтүдән кулланучы һәрбер кешенең фикерен өйрәнү эшен дәвам иттерергә;

хезмәтләр күрсәтүдән инвалидларның файдалана алуына аерым игътибар бирергә;

4) социаль хезмәт күрсәтү оешмалары буенча:

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, опека органнары арасында җаваплылык һәм вәкаләтләр зоналарын бүлешүне күздә тотарга;

«Уңайлы мохит» программасын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

аеруча өлкән яшьтәгеләр арасында, электрон сервислардан файдалануда уңайлылыкны арттыру, өлкән яшьтәге гражданнарны өйрәтү эшен дәвам иттерергә;

балалар өчен түгәрәкләр эшен киңрәк җәелдерергә;

рәсми сайтларда «күзләре начар күрүчеләр өчен» режимында яхшырак күренсен өчен югары сыйфатлы документлар куярга;

җитәкчеләр һәм белгечләрнең квалификациясен күтәрүне оештырырга;

социаль хезмәтләр күрсәткәндә инновацияле (заманча) технологияләр куллануны гамәлгә ашырырга;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре хезмәткәрләренә аларның эшләре үзенчәлеген исәпкә алып дәресләр, психологик бушану тренинглары уздырырга;

оешманың рәсми сайтындагы төп сәхифәдә гаиләләр һәм өлкән кешеләр өчен булачак чаралар турында белдерүләр урнаштырырга.

6. Сыйфатны бәйсез бәяләү йомгаклары буенча социаль өлкә оешмаларының эшчәнлеген камилләштерү өчен күрелә торган чаралар.

СББ йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының сыйфатны бәйсез бәяләүне уздыру иҗтимагый советлары тәкъдимнәре нигезендә бәяләүне үткәрү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча конкрет чаралар каралган планнар расланды. Планнар www.bus.gov.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары рәсми сайтларында урнаштырылган.

Аларда төзекләндерү эшләре, инвалидларга хезмәт күрсәтүдә аларга башкалар белән беррәттән хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге бирә торган уңайлы шартлар, һәркемгә куллану мөмкинлеге бирә торган шартлар булдыру өчен оештыру чаралары, социаль өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, өлкән яшьтәге гражданнар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар белән эшләү технологияләрен кертү, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән башка чаралар каралган.

СББ йомгаклары буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча расланган планнарны үтәүгә контрольне оештыру www.bus.gov.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан сыйфатны бәйсез бәяләү йомгаклары турында мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән гражданнарның рәсми сайтны каравын һәм аларның фикерләрен мониторинглауны алып бару, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү эшен оештыру һәм рәсми сайтта күрелгән чаралар турында гражданнарга мәгълүмат бирү, ведомство контроле кысаларында, шул исәптән СББ уздыру иҗтимагый советлары әгъзаларын эш төркемнәре составына кертү юлы белән дә, контроль чаралар уздыру өчен җаваплы затларны билгеләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

СББ йомгаклары буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча расланган планнарны һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары уздырган киңәшмәләрдә кабул ителгән карарларның үтәүгә контрольне гамәлгә ашыру максатларында 2018 елда СББ процедурасын узган учреждениеләр җитәкчеләре чыгышлар ясады.

СББ йомгакларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт һәм муниципаль оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан оешмаларның хезмәт коллективларын һәм аларның җитәкчеләрен премияләү, оешмалар җитәкчеләренә карата СББ йомгакларыннан һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәүдән чыгып, стимуллаштыру характерындагы чаралар куллану, әлеге шартны оешмалар җитәкчеләренең хезмәт килешүләренә кертү, оешмалар җитәкчеләрен һәм хезмәт коллективларын рәхмәт хатлары белән бүләкләү, оештыру-боеру чараларын куллану, җитәкчеләр составын алыштыру кебек карарлар кабул ителә. Югары рейтинглы оешмаларны бүләкләү, түбән рейтинглы оешмаларга карата чаралар күрү түрендәге карарларны шулай ук СББның тулы циклы тәмамланганнан соң кабул итү планлаштырыла.

7. Халыкка мәгълүмат бирү, аңлату эшчәнлеге.

СББ ны башкару кысаларында Татарстан Республикасында халыкка мәгълүмат бирү, аңлату эшләре алып барыла:

халыкка, җәмәгатьчелек һәм һөнәри берлекләр вәкилләренә СББ турында мәгълүмат бирү буенча чаралар планнарыраслана;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары рәсми сайтларында хезмәтләрдән кулланучыларга социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфаты турында үз фикерен белдерү мөмкинлеге бирелде, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында фикерләр һәм тәкъдимнәр өчен «почта ящиклары» куелды;

республиканың муниципаль оешмаларында иҗтимагый оешмалар (ветераннар, инвалидлар оешмалары һ.б.) вәкилләре белән гражданнарны СББ уздыруга тарту һәм социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфаты турында фикерләрен белдерүне активлаштыру максатларында очрашулар оештырылды;

СББ мәсьәләләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары коллегияләре утырышларында, Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашындагы брифингларда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында карап тикшерелә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында www.bus.gov.ru рәсми сайтына сылтамалар һәм социаль өлкә оешмаларының хезмәт күрсәтү сыйфаты шартларын бәяләү өчен интерактив анкета формалары урнаштырылган.

гражданнарга җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү өчен күрелгән чаралар турында мәгълүмат гражданнар җыеннарында, мәгариф оешмаларында ата-аналар җыелышларында, гомуми җыелышларда бирелде.

Татарстан Республикасында СББ процессын гамәлгә ашыру социаль өлкә оешмалары эшенең сыйфатын яхшыртуга, иҗтимагый оешмаларның һәм һөнәр берлекләренең бу эшне башкаруда активлыгын арттыру өчен шартлар булдыруга юнәлтелгән, шулай ук ул җәмәгать контроленең бер рәвеше дә булып тора.

2020 елда социаль өлкә оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәя бирүне уздыру өчен кирәкле шартлар тәэмин итүгә, шулай ук СББ турында һәм анда хезмәтләрдән кулланучы гражданнарның үзләренең катнашуы турында массакүләм мәгълүмат чаралары һәм социаль челтәрләр аша халыкка мәгълүмат бирүгә, аңлатуга юнәлтелгән эш дәвам иттереләчәк.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов